ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 гыйнвар 2025ел № 558

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3678 номерлы Карары белән расланган планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Милли киңлек мәгълүматлары системасы» бердәм цифрлы платформасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 7 июнендәге 1040 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3678 номерлы Карары белән расланган планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.3.3.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән һәм шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә

торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

2) 3.4.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3) 3.5.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

4) 3.6.1 пунктта:

- икенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.»;

- алтынчы абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Техник мөмкинлек булганда процедураларны башкару, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов